ИНСПЕКЦИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ
КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

07.11.2022 Казан шәһәре № 123

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибен раслау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын били торган затлар һәм башка затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Указы нигезендә боерык бирәм:

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибен (алга таба – Тәртип) (кушымтада бирелә) расларга.

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга.

3. Хокукый эш һәм өлешле төзелешне тикшерүдә тоту идарәсенең юридик бүлегенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Җыелма анализ һәм мәгълүмат технологияләре бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәсхи кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибен раслау турында» 2016 елның 15 февралендәге 11 номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

6. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче В.А. Кудряшов

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелеш күзәтчелеге
инспекциясенең 2022 елның
7 ноябрендәге 123 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе җитәкчесе аларга карата эшкә яллаучы вәкиле булып торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – граждан хезмәткәрләре, Инспекция) тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү процедурасын билгели.

2. Хәбәр граждан хезмәткәре тарафыннан әлеге Тәртип кушымтасында китерелгән форма буенча язмача формада вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында белдерү рәвешендә (алга таба – белдерү) формалаштырыла һәм Инспекция җитәкчесенә җибәрелә.

3. Инспекция җитәкчесе белдерүне, алдан карау өчен, өч эш көне дәвамында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) җибәрә. Җаваплы зат белдерүне алган көнне аны белдерүләрне теркәү журналында терки.

4. Белдерүне алдан карау барышында җаваплы зат белдерүне җибәргән граждан хезмәткәреннән анда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар алырга хокуклы. Мәгълүмат алу өчен, Инспекция тарафыннан дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм мәнфәгатьле оешмаларга гарызнамәләр җибәрелә ала, шулай ук, гарызнамәләр җибәрүне дә кертеп, коррупциягә каршы тору өлкәсендә «Посейдон» дәүләт мәгълүмат системасы да кулланылырга мөмкин.

5. Белдерүне алдан карау нәтиҗәләре буенча җаваплы зат дәлилләнгән бәяләмә әзерли. Белдерү, бәяләмә һәм алдан карау барышында алынган башка материаллар җаваплы зат тарафыннан белдерү алынган көннән башлап җиде эш көне эчендә аның тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе (алга таба – Комиссия) рәисенә тапшырыла.

6. Әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьләр юлланган очракта, белдерү, бәяләмә һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан белдерү алынган көннән башлап 45 көн эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок Комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артыгракка түгел.

7. Белдерү, бәяләмә һәм башка материаллар Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмә нигезендә Комиссия тарафыннан карала.

______________

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибенә кушымта

Үрнәк

________________________________
(танышып чыгу турында тамга)

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтүчелеге инспекциясе җитәкчесенә

________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

кемнән

________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта),

________________________________________
били торган вазыйфа)

**Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында белдерү**

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә миндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәр итәм (кирәклесе астына сызарга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүгә нигез булган шартлар: _____________
__________________________________________________________________

Минем шәхси кызыксынучанлыгым аларны үтәүгә йогынты ясый яки йогынты ясарга мөмкин вазыйфаи бурычлар: _________________________________
__________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу һәм җайга салу буенча

тәкъдим ителә торган чаралар: ___________________________________________
_____________________________________________________________________

Әлеге мөрәҗәгатьне караган вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим/ниятләмим (кирәклесе астына сызарга).

«____» ____________ 20___ ел. _____________________ ________________________
(белдерүне җибәргән затның имзасы (тулы имза)

_________________